Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәтү бар"
(Коръән Кәрим. 2:256)

Исләм нуры

№ 12 (640) 20 июнь, 2017 ел (1438, Рамазан) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга 12+

# Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинның ураза гаете белән котлавы



Бисмиллаһир-рахманир рахим!

Әссәләәмүгәләйкүм үә рахмәтуллаһи үә бәрәкәәтүһ!

Мөхтәрәм дин кардәшләребез!

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте һәм шәхсән үз исемемнән ихластан Ураза гаете белән котлыйм!

Һәр мөселман өчен Ураза Гаете иң мөбарәк бәйрәмнәрнең берсе. Ураза тәмамлануын белдерүче бу бәйрәм бар җиһанны яралткан Аллаһка мәхәббәтебез билгесе. Мөхәммәд Пәйгамбәр саллаллаһу гәләйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә әйткән: «Әгәр минем өммәтем кешеләре Рамазанның савабы ни дәрәҗәдә зур икәнен белсәләр, алар Рамазан ел буе дәвам итүен теләр иделәр». Аллаһы Тәгалә кушканнарга хөрмәт күрсәткән татарстанлыларга үземнең ихлас рәхмәтемне белдерәм.

Соңгы елларда ураза һава температурасы иң югары билгеләргә күтәрелгән җәйге айларга туры килә. Аллага шөкер, бу юлы безгә бернинди киртәләр дә Аллаһ каршындагы бурычларыбызны үтәргә, мохтаҗлар өчен тагын да күбрәк миһербанлы гамәлләр кылырга комачауламады.

Шуның белән бәйле рәвештә безгә һәрвакыт Мөхәммәд Пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең сүзләрен истә тотарга кирәк: «Кем күршесе ач икәнне белә торып, йокларга ята, шуның иманы зәгыйфь һәм ихлас түгел!».

Татарстан мөселманнары Ураза бәйрәмен шатланып каршы алалар, чөнки хәдисләрдән билгеле булганча: «Ураза тотучының ике шатлыгы булыр: ифтар шатлыгы һәм Аллаһы Тәгалә белән очрашу шатлыгы».

Ураза тотучыларның догалары кабул булып, кешеләр үзләренең гөнаһларыннан арына алса иде! Изге Рамазан дәвамында Аллаһ Раббыбызга гыйбадәт кылып омтылган мәңгелек тормыш кыйммәтләре һәр мөселманның төп максаты булсын!

Ислам традицияләре, башка дөньяви диннәр кебек үк, гаделлек, мәрхәмәтлелек, игелеклелек кебек мәңгелек кыйммәтләргә һәм якыннарыңны нинди милләттән, диннән булуына карамастан кайгыртуга нигезләнгән.

Раббыбыз татарстанлыларга ике дөнья рәхәтен бирсен, барлык традицион конфессияләргә тыныч һәм килешеп яшәргә, гыйлем белән өммәтебезне нығытырга ярдәм итсен! Әмин!

Ихтирам һәм изге догалар белән.

# Ураза гаетебез мөбарәк булсын!



Мәрхәмәтле, Рәхимле Аллаһ исеме белән!

Мөхтәрәм дин кардәшләр!

Үзәкләшкән дини оешма — Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең Чаллы шәһәре мөхтәсибәте һәм дә үз исемемнән барчагызны изге Рамазан ае тәмамланып Гайдел-Фитыр — Ураза бәйрәме җитүе белән ихлас котлыйм! Аллаһы Тәгалә ошбу айда Үз ризалыгы өчен кылган барча изгелекләребезне, тоткан уразаларыбызны, мохтаҗларга биргән хәер-садакаларыбызны, барча гыйбадәтләребезне кабул итеп тиешле әҗер-савапларын насыйп әйләсә иде!

Рамазан аенда тәкъвалыгыбыз, Аллаһыга булган мәхәббәтебез җитди сыналу үтте. Иң озын җәйге көннәрдә Аллаһының әмерен үтәп аштан-судан, уразаны бозарга мөмкин булган гамәлләрдән тыелып тордык, көндәлек биш вакыт намазны үтәү белән бергә төнге намаз — тәрәвихларны укыдык, башка изгелекләр кылдык. Рия — кешеләр күрсен өчен түгел, ә Аллаһының рәхмәтенә ирешү теләге белән. Һәм Аллаһы Тәгалә Үзенең ярдәмнәрен — җиләс, эссе булмаган көннәрен бирде, күңелебездә киләчәккә өмет уятты. Тоткан уразаларыбыз, төнге намазларыбыз, кылган изгелекләребез белән калебебезне сафладык. Аллаһ Раббуль Гыйззә әйтә: "Сафланган кеше генә уңышка ирешер. Раббысының исемен искә алучы һәм намаз укучы" (87: 14-15).

Бәйрәмебездә төп гыйбадәт — гает намазы. Аңа кадәр мохтаҗ-мескеннәргә фитыр садакаларыбызны тапшырып бетерсәк иде. Чөнки мохтаҗ-мескеннәр дә бәйрәм шатлыгы кичерсен, бу көннәрне генә булса да мохтаҗлык сизмәсен. Быел аның күләме акчалата 100-600 сум (соңгысы зәкят түләүчеләр өчен). 2017 елга зәкят нисабы 198 мең сум.

Ураза Гаетен бәйрәм итү шәһәребез мәчетләрендә 25 июньдә иртәнге 07.00 сәгатьтә бәйрәм вәгазьләреннән башлана. Аннары, Аллаһы насыйп итсә, Гает намазы укылыр. Мәчетләребезгә рәхим итегез!

Рамазан аенда ирешкәннәрне, күңелебезгә туплаган рухи кыйммәтләребезне киләчәктә дә саклый алсак иде. Аллаһы Тәгалә тоткан уразаларыбыз, укыган намазларыбыз, кылган барча изгелекләребез бәрәкәтендә тормышыбызны тагын да күркәмрәк итсен, изге ният — максатларыбызга ирешергә юлларын ачсын! Өйләребездә һәрвакыт тынычлык, татулык, муллык булсын! Киләчәктә дә гыйбадәтләребез дәвамлы булып Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә лаек яшәргә насыйп әйләсен!

Ихтирам һәм изге догалар белән,

**Әлфәс хәзрәт Гайфуллин.**
**Чаллы шәһәре имам-мөхтәсибе,**
**ҮДО – ТҖМ ДН Президиумы әгъзасы.**

# Кеше исламга яраклашырга тиеш

Аллаһ тәгалә безгә Коръәни-Кәримдә ачык итеп әйтә: (5.3.) «Бүген динегезне камил кылдым һәм сезгә Үземнең нигъмәтемне тәмам кылдым, һәм динегезнең Ислам дине булуы белән риза булдым».

Динебез — Ислам, ул камил, ул тәмам. Аңа бернәрсә дә өстәргә дә кирәкми, аннан бернәрсә дә алырга да кирәкми. Ислам дине биш баганага нигезләнә һәм аның камиллеге — шушы биш баганаың тәгәл үтәлүендә. Кем дә булса диндә кимчелек күрә икән, чынлыкта, бу кимчелек диндә түгел, бәлки ул кешенең үзендә яисә кимчелек күрсәткән кешенең динне камил тотмавында. Аллаһ тәгалә әйтә: (3.85.) «Берәү Ислам диненнән башка дингә иярсә, аның дине вә гамәле һич кабул булмый һәм ул ахирәттә хәсрәтләнүчеләрдән булыр».

Ягъни, әгәр кем дә булса үз теләкләренә, күңеленә ияреп, Ислам диненә нинди дә булса өстәмәләр кертә, яисә Ислам диненнән нәрсә дә булса чыгара башлый икән, ул дин Ислам дине булудан туктый, башка дингә әверелә һәм шул башка дингә иярүчеләр кыямәт көнендә хәсрәтләнүчеләрдән булыр.

Аллаһы тәгалә атабыз Адәмне һәм аның нәселе булган барча халыкны Ислам динендә генә яши ала торган итеп халикъ кыла. Аллаһы тәгалә кешелекнең яшәеш дәверендә бик күп пәйгамбәрләр җибәрә. Пәйгамбәрләренә ияргән халыклар зур уңышларга ирешәләр, иярмәгәннәре һәлакәткә дучар булалар. Аллаһ тәгалә әйтә: (42.13.) «Ий, кешеләр, Ий, мөселманнар! Без сезгә Ислам диненнән шәригать хөкемнәрен төзеп бирдек һәм аның юлын, дәлилләрен күрсәттек. Ул шәригатьне Нух пәйгамбәргә һәм сиңа, ий Мөхәммәт галәйһиссәлам, вәхи кылдык, ул шәригатьне Ибраһимга, Мусага һәм Гайсә галәйһиссәламгә йөкләдек. Шушы шәригатьне тотыгыз һәм шушы шәригатьтә төрле фиркаларга бүленмәгез!».

Сәхәбәләр шушы хакыйкатьне аңлаганнар, күп сораулар бирмичә пәйгамбәребез салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләмгә ияргәннәр. Аны әхлакта, үзара мөнәсәбәттә, кыскасы, бөтен нәрсәдә үзләренә үрнәк итеп алганнар, аңа авырлык китерүдән элек үзләренә авырлык китерүне өстен күргәннәр. Алай гына түгел, алар бер-берсенә карата да зур ихтирам күрсәткәннәр, сугыш кырында суга тилмергән вакытларында да үзләре эчмичә башкаларга әчергәннәр. Алар Коръәнне, чын мәгънәсендә, үзләренә тормыш өчен куллану кануны итеп кабул иткәннәр.

Ислам дине кабул итеп аларның юашлары усалланган, усаллары юашланган. Алар үзләренең әхлакларын Коръән кысаларында тәрбияләгәннәр. Пәйгамбәребез салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләмнең вафатыннан соң хәлифә булып Әбү Бәкр радый Аллаһу ганһе сайлана. Гарәп ярымутравындагы исламга дошман булган бөтен кеше шатлана. «Андый юаш кеше булганда без ислам динен бетерәчәкбез», - диләр. Ә, карагыз, Әбү Бәкр радый Аллаһу ганһенең 2 ел хәлифә булып тору дәверендә ислам дине гарәп ярым утравында гына түгел, бәлки Гыйрак, Шам җирләренә дә тарала. Вафаты алдыннан ул үз урынына хәлифә итеп Гомәр радый Аллаһу ганһене билгели һәм бу хакта башкаларның фикерләрен сораша. Аңа Гомәр радый Аллаһу ганһүне кырыс, каты холыклы кеше, диләр. Ул җавап итеп: «Бүген ул кешеләргә кырыс һәм каты булып күренә, чөнки мин кешеләргә йомшак. Кайчан эшләрне ул үзе алып бара башлый, ул түбәнчелеклерәк булачак», - ди. Бу ике хәлифә өммәт белән идарә итә башлагач та үзләренең әхлакларын Исламга яраклаштыралар, аларның тормышлары Коръән белән, сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләмнең сирасы белән тәңгәлләштереп алып барыла башлый. Бер-берсенә капма-каршы холыклы булган бу ике бөек шәхесне Аллаһы тәгалә бер-берсенә тиң булган, башкалар ирешә алмас дәрәҗәләргә ирештерә. Хәтта аларның кайсы юаш, кайсы кырыс икәнлеген төгәл генә әйтеп тә булмый.

Пәйгамбәребез салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең вафаты алдыннан Мут сугышы вакытында византиялеләргә ярдәм иткән Сүрия белән чиктәш кабиләләрне буйсындыру максаты белән Усама ибне Зәйд җитәкчелегендә гаскәр хәзерли, әмма максатын тормышка ашыра алмыйча вафат була. Әбү Бәкр радый Аллаһу ганһе хәлифә булгач Пәйгамбәребез салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләмнең максатын тормышка ашырырга алына. Пәйгамбәребез салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләмнең үлеме сәбәпле күп кенә кабиләләр Ислам диненнән яңадан мәҗүсилеккә кайта башлыйлар. Бу хәлгә сәхәбәләр бик борчылалар. Алар гаскәр чыгып киткәч, мөшрикләрнең Мәдинәгә һөҗүм итүеннән куркалар. Аларны гаскәр башына 18 яшьлек Усаманың куелуы да борчый. Алар Усама урынына олырак яшьтәге кеше куелса яхшырак булыр иде дип киңәшләшәләр. Алар үзләренең борчылуларын җиткерергә һәм шуның белән Әбү Бәкр радый Аллаһу ганһене бу уеннан кире кайтарып булмасмы дигән ниятләр белән Гомәр радый Аллаһу ганһене Әбү Бәкр радый Аллаһу ганһе янына кертәләр. Үзенең юашлыгы белән билгеле булган Әбү Бәкр радый Аллаһу ганһе үзенең усаллыгы белән билгеле булган Гомәр радый Аллаһу ганһенең сакалыннан өстерәп йөртә һәм аңарга: «Синең анаңның мондый улы булмасын! Ничек итеп син миннән пәйгамбәребез үзе куйган кешене алуны сорый аласың? Үзенең кулында минем җаным булган зат белән ант итәм! Бел, хәтта миңа ерткыч хайваннар ташланса да һәм мине ботарласалар да мин Усама гаскәрен җибәрү карарын раслар идем», - дип әйтә. Гомәр радый Аллаһу ганһе хәлифә яныннан елап чыга һәм иптәшләренә: «Сезнең аркада миңа хәлифәдән эләкте», - ди. Алар Аллаһ ризалыгы өчен усалланалар, Аллаһ ризалыгы өчен юашланалар һәм мондый халәтләр аларның үзара мөнәсәбәтләренә тискәре йогынты ясамый. Алар зур сәясәт белән шөгыльләнеп мохтаҗларны, рәнҗетелгәннәрне, ягъни гавәм халыкның мәнфәгатьләрен дә игътибардан читтә калдырмыйлар.

Әбү Бәкр радый Аллаһу ганһе хәлифәлек иткән чорда Мәдинәдә бер мохтаҗ сукыр карчыкка Гомәр радый Аллаһу ганһе барып ярдәм итеп йөри торган була. Ул күп вакыт үзеннән башка икенче бер кешенең дә шул карчыкка ярдәм иткәнен белгән һәм кем икәнен белер өчен саклап торган. Хәлифәнең ярдәм иткәнен күргәч: «Мохтаҗларга кем ярдәм итә икән дип торган идем, монда да Әбү Бәкр җитешкән икән», - диде. (Тарих ибн Әсир, 2җ, 62 с.). Бу ике олугъ сәхәбәнең тормышын кайсы яклап кына карасак да игътибарга, алардан үрнәк алырга лаек дип табарбыз.

Гомумән алганда, барлык сәхәбәләрнең дә тарихларын өйрәнү безгә Ислам динен ныграк аңларга ярдәм итә. Чөнки алар күңелләре белән Ислам динен кабул иткәннәр, пәйгамбәребез салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләмгә ихласлык белән ияргәннәр, ул пәйгамбәребез салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләм алар өчен бөтенесе булган. Коръән, сөннәт аларның тормышы өчен алыштырмас бер өлге булып торган. Алар Коръәнне бүгенге көндәге кебек мактанышыр өчен ятламаганнар, бәлки ятлый барган һәр аятен үзләренең тормышларына кертә барганнар. Алар чын мәгънәсендә пәйгамбәребез салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләмнең дәвамчылары һәм мөселманнарның иң яхшылары булганнар. Шуңа күрә дә пәйгамбәребез салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләм алар турында: «Минем өммәтемнең иң яхшы буыны булып шулар торадыр, кемнәр вакытында мин җибәрелгән идем», дип әйтә.

Сәхәбәләр турында Аллаһы тәгалә Коръәни-Кәримдә аерып әйтә: (9.100.) "Мәккәдән Мәдинәгә күчеп килгәннәрдән ярышта әүвәл алга чыгучылар, ягъни Аллаһуга вә расүлгә итагать итүдә һәм ислам динен куәтләү юлында һәрвакыт алда йөргән Мөһаҗирләр, һәм яхшылыкта Мөһаҗирләргә иярүче төп Мәдинәле ансарлар — ярдәм итүчеләр, һәм аларга ияргән башка мөселманнар, алардан Аллаһ разый булды һәм алар Аллаһудан разый булдылар. Вә аларга асларыннан елгалар ага торган җәннәтләр хәзерләнде, алар анда мәңге калырлар." Җәннәтләргә кереп анда мәңге калу — зур уңышка: мәңгелек бәхеткә ирешүдер.

Һәр сәхәбәнең тормышы өйрәнүгә лаек. Бүгенге үзен мөселман санаган күпләр гыйбадәткә күп бирелеп дөньяларга калудан куркалар. Дөнья малы өчен вәгъдәсезлек, хыянәт аларның мөселман булуларын да шик астына куя. Гарәпләргә карата әйтелсә дә, әйтерсең, Аллаһы тәгалә Коръәндәге түбәндәге аятьләрне бүгенге мөселманнар турында әйтә. Аллаһы тәгалә әйтә: (49.14.) "Бәдәви гарәпләре әйттеләр: «иман китердек», - дип, син әйт: «Сез иман китермәдегез, ләкин «мөселманнардан куркып, яки файдаланып көн күрү өчен тыштан гына Ислам динен кабул иттек»,-дип әйтегез. Әле күңелегезгә иманның әсәре дә кергәне юк, иман китерергә ниятегез юк, имансыз гына мөселман булып йөрергә телəгәнсез, ягъни мөселманнар белән гамәл кылып, аларны алдарга телəгәнсез. Әгәр чынлап та иман китереп ихлас күңел белән Аллаһыга һәм аның расүленә буйсынсагыз, мөселманнар белән кылган гамәлләрегезгә һич кимчелек ирешмәс иде, савабы, әлбәттә, югалмас иде. Чынлыкта, Аллаһ ярлыкаучы һәм рәхмәт итүчедер."

Алда әйтеп кителгәнчә, Аллаһы тәгалә атабыз Адәмне балчыктан ярата, аның кабыргасыннан анабыз Һаваны ярата. Ул аларны үрчи торган, нәсел калдыра торган, кавем-кавем итеп һәм Үзенә генә гыйбадәт кылырга тиеш итеп яраткан. Раббысына гына гыйбадәт кылган халыклар, җиңүгә ирешәләр, һәрьяклап алга баралар. Дөньядан ваз кичкән мөселманнар шул дөнья белән идарә итәләр. Дөнья үзенең бөтен байлыклары белән үзе үк аларга буйсына.

Мәсәлән, Сәлмән әл-Фариси Фарсы иленнән, Исфахан өлкәсе, Джайан авылыннан була. Атасы авылның старостасы, бай һәм дәрәҗәле кеше. Атасы улын шул кадәр ярата, хәтта яшь кызларны бикләгән кебек улын аерым бер бүлмәгә бикләп куя. Бервакыт ул атасының йомышын үтәргә дип өеннән чыга, әмма тиешле урынга барып җитә алмый, бер христиан дин әһеленә юлыга, аңа аларның дине бик охшый һәм бу диннең асылын эзләп Шам җирләренә чыгып китә. Ул хаклыкны эзли торгач, гарәп ярым утравында пәйгамбәр киләчәк дигән хәбәрне ишетә һәм пәйгамбәрне күрер өчен хәтта коллыкка төшә. Ул теләгенә ирешә — пәйгамбәрне күрә, аны алдан кисәтелгән билгеләреннән таный, аны елый-елый үбә башлый һәм үзенең тарихын сөйли. Сәлмән әл-Фариси мәшһүр сәхәбәләрдән булып Ислам диненә бик күп файдалар китерә. Ә иң гаҗәбе: пәйгамбәрне күрер өчен дөньядан ваз кичкән, коллыкка төшкән, пәйгамбәрне күргән, аңарга ияргән һәм пәйгамбәр аны үзенең гаилә әгъзасыннан дип атаган. Ул фарсыларның башкаласы булган Мадаин шәһәрен алганда зур роль уйный һәм аннары шул шәһәрнең башлыгы була.

Ислам диненең максаты илләр, җирләр басып алу, хәлифәтләр төзү түгел, бәлки Ислам динен тарату. Пәйгамбәребез салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләм дә төрле дәүләтләргә хатлар җибәргәндә фәкать Ислам диненә өндәп кенә яза. Аларның күбесе Ислам динен кабул итми, әмма, тарихтан күргәнебезчә, күпмедер вакытлар үткәч бу дәүләтләр, халыклар Ислам динен кабул итәләр.

Ислам динен күңелләре белән кабул иткән мөселманнар мөмкинлекләренә карап пәйгамбәрләренә ярдәм итәргә тырышалар, үзләренең балаларын Расүлуллаһ галәйһиссәламгә хезмәткә, тәрбиягә бирәләр. Расүлуллаһ галәйһиссәлам һиҗрәт кылгач, Үммү Сүлим аның янына килеп: «Я, Расүлуллаһ! Ансарларның ирләре, хатыннары сезгә бүләкләр бирәләр. Минем бүләк итәрлек һичнәсәм юк. Әгәр дә кабул итсәгез, шушы балам сездә хезмәттә булсын. Үзе язу да белә, үткен баладыр», -диде. Бу бала Расүлуллаһ галәйһиссәламгә 10 ел хезмәт итте, Расүлуллаһ галәйһиссәламнән 2286 хәдис риваять иткән бу баланың исеме Әнәс ибне Мәлик була.

Бу Ислам дине килгән, дөньяга тарала башлаган вакытлар. Әмма бу мөселманнарга икенчеләре килә, аларга алмашка икенчеләре килә. Сәхәбәләр тормышы китапларда, уку әсбапларында гына кала. Алар мисалында тормыш алып баручылар буыннан буынга кими, ахырда мөселманлар түбәнчелеккә төшеп, европалылар кул астында калалар. Алар инде дөнья белән идарә итү, дөнья байлыкларына ия булу вазыйфасын тиешенчә алып бара алмый башлыйлар. Бүгенге мөселманнар телдән җәннәткә омтылабыз, җәһәннәмнән Аллаһы тәгаләгә сыенабыз, дисәләр дә гамәлдә беренче мөселманнардан бик ерак. Бүген Ислам дине минем өчен әһәмиятлерәк дип, гыйбадәт кылу өчен уңай шартлы эш сайлаучылар да, балам Ислам динендә тәрбияләнсен дип, балаларын Ислам динендә тәрбияләүчеләр дә юк дәрәҗәсендә бик сирәк. Югыйсә, Татарстаныбызның президенты да, гаедләрдә күрәбез, намаз укый, мөселман балалары өчен мәктәпләр дә бар, теләгән кешегә балалар бакчалары да бар. Күпләрдән Ислам динен мәҗбүри кертергә кирәк дигән сүзләр ишетергә туры килә. Ислам дине мәҗбүрилеккә корылмаган. Аллаһы тәгалә әйтә: (2.256.) "Дингә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәтү бар." Ясалма, ялган, батыл диннән Аллаһ төзегән хак дин ачык аерылды. Теләгән кеше Коръән, сөннәт юлы белән барып җәннәткә керсен! Моны теләмәгән кеше бидегәт, хорафәт юлы белән барып җәһәннәмгә керсен. Берәү Аллаһудан башканы Иләһе тотуны инкяр итеп, Аллаһуга нык ышанса һәм бидегәт, хорафәтләрдән ерак булса, ул мөэмин һич тә өзелми-сынмый торган тоткага ябышты. Аллаһ ишетүче һәм белүче.

Бөтен томышның мәгънәсе дә иреклелектә. Шушы кыска гына гомердә кеше үзе сайлый үзенең ахирәтен. Шуның өчен дә кыямәт көнендә үпкәләргә сәбәп булмаячак. Чөнки барыбыз өчен дә шартлар бер. Аллаһы тәгалә барчаларыбызны да үзенең сөекле колларыннан кылып, ахирәттә дә вәгъдә ителгән җәннәтләргә ирешүчеләрдән насыйп кыйлса иде.

**Рөстәм хәзрәт Шәйхевәли,**
**Чаллының "Ак мәчет"е имам-хатыйбы,**
**төбәк казые.**

# Сорау вә җавап

**Әссәләмегаләйкүм, "Ислам нуры"н башкаручылар!**

**Мин 1995 елдан Ташяткан авылының "Рамазан" мәчете имамы. Мин мәрхүмнәргә Коръән хәтем уздырганда садака өләштерү белән килешмим. Мәҗлестә 30-40 кеше була. Һәркем садака өләшә. Бу 30-40 кеше бер-берсенә садака бирә. Бирәү 2 сумлыкларны тарата, икенчеләр 5 сумлыкны. Кайберләре 1 сумны да бирә. 91 яшьлек бер әби мәрхүм булгач бик күп кеше булды. Мин бу мәҗлестә садакаларны мәчеткә бирергә тәкъдим иттем. Әмма бер әби, садака бирүче садаканы үзенә савап булсын дип бирә, синең теләгең дөрес түгел, дип авызымны япты.**

**Соравым шул: Татарстанда, мөселман илләрендә мәрхүмнәргә Коръән укыганда садака өләшәләрме? Нинди тәртиптә? Без дә сезгә иярер идек. Бездәге тәртипне ничек дип әйтәсез? Садака бирүнең тәртибен язсагыз иде.**

**Бу хатны җибәргәнче ике йортта искә алу мәҗлесе үткәрергә туры килде. Бу мәҗлесләрдә садаканы бер-берсенә түгел, ә мәчеткә бирергә сорадым. Нәтиҗәдә мәчеткә 4000 сум акча керде.**

**Рамазан Корманов.**
**Омск өлкәсе, Тәбриз районы,**
**Ташяткан авылы.**

Шәригатьтә садака өләшү дигән аерым бер тәртип каралмаган. Хәзерге вакытта кайбер урыннарда садака өләшәләр, икенчеләрендә юк. Безнең "Ак" мәчет" мәхәлләсенә килгәндә, мәҗлес үткәрүчеләр гадәттә мәчеткә, мәдрәсәгә дип бирәләр, мәҗлестәге һәрбер кешегә садака таратмыйлар. Чөнки без аларга шулай хәерлерәк икәнен аңлатып торабыз. Мәчет-мәдрәсә тирәсендә булмаган кешеләр булса, алар инде таратырга тырышалар. Ягъни тарату –таратмау хуҗаның үзенә бәйле булып кала.

Кайсы җирләрдә садакаларны мәчет-мәдрәсәләргә тапшыралар – ул җирләрдә мәчетләр эшләп тора, җылысына, утына түләргә җитеп бара. Ә садакалар мәчетләргә тапшырылмаган урыннарда алар ябык тора – утына, суына түләргә акчалары юк. Шуңа күрә дә садакаларны тиешле урынына бирү кирәк, һәркемгә таратып утыру дөрес түгел.

Садакалар өч төрле була: фарыз, важип һәм нәфел. Фарыз садакалар – зәкятләр, гошерләр. Аларның кемнәргә бирелергә тиешлеге Коръәндә әйтелгән – мескеннәргә, фәкыйрьләргә, юлдан өзелгән мөсафирларга, бу эшкә билгеләнгән зәкят җыючыларга (эшләре, кәсепләре булмаган очракта). Анда садака ияләре булган 7 төрле кеше атала. Шулардан иң күбрәге мескеннәргә һәм фәкыйрьләргә тиеш. Мескеннәр кемнәр алар? Ашарларына да җитми торган кешеләр. Ә фәкыйрьләр - зәкят бирерлек нисаблары булмаучылар. Хәнәфи мәзһәбендә ул көмеш нисабы буенча исәпләнә - бүгенге көндә 18 мең 200 сумнан артыграк акчасы, малы (алтыны, көмеше, сату товарлары) булмаган кеше фәкыйрь дип атала. Шуннан артык малы булган кеше бай хөкемендә санала, зәкәт түләргә тиеш була.

Важиб садакалар бар. Алар инде нәзерләр, кәффарәтләр. Әгәр бер кеше, фәлән-фәлән чаклы бирәм мескен-фәкыйрьләргә яки Аллаһы Тәгалә юлына дисә, бу инде нәзер садакасы була. Важиб садакалар да тиешле җиренә бирелә. Кәффарәтләр булса мескеннәргә, фәкыйрьләргә таратыла.

Өченче төрле садака - ул мөстәхәб яки башкача нәфел дип атала. Алар кеше өстендә мәҗбүри түгел, ихтыяри. Кеше әҗер-савап алыр өчен үз ихтыяры белән малын садака итеп бирә. Мондый садакалар шулай ук мескен-фәкыйрьләргә, дин юлына бирелә. Дин юлына дип әйтү ул инде мәчет-мәдрәсәләрне тоту өчен. Төрле кешеләргә изгелекләр кылу, юллар, күперләр салу, коелар казу, чишмәләр чыгару, дини китаплар бастыру, тарату – шушындый саваплы эшләргә үз ихтыяры белән садака бирсә алар инде нәфел садакалар. Алар шәригать буенча билгеләнгән эшләргә, кешеләргә бирелсә генә садакадан китә. Әгәр, мәсәлән, мәҗлестә байлар да булса (18 мең 200 сум акчасы булган кеше), андый кешеләргә ул садаканы алу, беренчедән, хәрам була. Аны алып ашасалар, хәрам ашаган булалар. Алган очракта да аннан котылырга, ягъни мескен-фәкыйрьгә, Аллаһы юлына тапшырырга тиешләр.

Шулай ук байларга белә торып садака бирү дә дөрес түгел, гөнаһ була. Һәм ул садакадан китми, бернинди әҗер-савабы да булмый. Шуңа күрә мәҗлестә садака бирүчеләр, кеше тарата, дип таратырга тиеш түгел, ә садакаларны үз урынына тапшырырга бурычлы.

Пәйгамбәребез (с.г.в.) садака турында болай дигән: "Ярты хөрмә биреп булса да җәһәннәм утыннан сакланыгыз!" Әлбәттә, ярты хөрмә бирү дигән сүз садакаларның мохтаҗ кешеләргә бирелергә тиешлеген күрсәтеп тора. Бай кешегә ярты хөрмә бирсәң, ул аны мыскыл итү дип кабул итәчәк. Ләкин ач булган мохтаҗ кеше әз булса да аңа шатланачак.

Мөстәхәб, нәфел булган садакаларны фәкыйрь кеше үзе дә бирергә мөмкин. Ләкин фәкыйрь кеше биргәндә үзеннән дә мохтаҗрак кешегә бирергә тиеш, әгәр аның әҗер-савабына ирешергә теләсә. Чөнки садакалар әҗер-саваплар бирә һәм җәһәннәм утыннан саклый. Әгәр садака итеп таратыла икән, имам кеше аңлатырга тиеш: садака була, әгәр ул мескеннәргә, фәкыйрьләргә, дин юлына бирелсә генә. Хат авторы ике мәҗлестән 4 мең сум керүе турында әйтә. Садакалар шулай тиешле урынга бирелсә, ул мәчет-мәдрәсәләрне тотарга җитәр иде.

Мөселманнар яшәгән мәхәлләләрдә мәчет-мәдрәсәләрне мөселман халкы тотарга тиеш. Хат авторы, имам кеше буларак, бу очракта бик дөрес эшләгән. Мәҗлестә мескеннәр, фәкыйрьләр булса, атап аларның үзләренә бирелергә тиеш, ә мәҗлестә утырган бар кешеләргә дә түгел. Хәзерге вакытта байтак кешеләр шәригать буенча байлар хөкеменә керә. Чөнки 18 мең 200 сумга 600 гр. көмеш сатып алырга була. Ә 600 гр. көмеш сатып алырлык кеше бай санала.

***Укучыбыз соравына җавапны шәригать белгече Рәфыйк хәзрәт Миннеәхмәт бирде.***

# Сорый белсәң – теләк, сорый белмәсәң…

Нурулла хәзрәт мәчеттәге бүлмәсендә Коръән укып утырганда, кемдер кыяр-кыймас кына ишек шакыды. Укый башлаган аятен тәгәлләп, "садәкаллаһүлгәзыйм" дигәннән соң, хәзрәт башын күтәреп, ишек шакучыга дәште:

— Әйе, кем бар анда, рәхим итегез!

Менә ишек ачылды һәм бүлмәгә башына яулык япкан, матур хиҗап күлмәк кигән урта яшьләрдәге мөлаем бер хатын керде. Киеменнән генә түгел, нурлы йөзе белән күз карашыннан да аның гамәл-гыйбадәт кылучы мөслимә булуы аңлашыла иде. Сәлам биреп исәнләшкәннән соң, ханым, өстәл янындагы урындыкка утырып, болай диде:

— Хәзрәт, үземне борчый торган бер сорау белән килдем әле мин сезгә. Мөмкинме?

— Нишләп мөмкин булмасын? Бик хуп, Аллаһ ярдәме белән җавап бирергә тырышырбыз, иншә Аллаһ...

— Эш шунда ки... минем инде күптән тормышка ашырасы килгән бер теләгем, алай гына да түгел — олы бер хыялым бар. Ләкин көнен дә, төнен дә дога кылып сораганыма карамастан, әлеге хыялым нигәдер тормышка ашмый... Догам кабул булсын өчен миңа берәр киңәш бирә алмассыз микән?

— Дога кабул булсын өчен Аллаһ кушканнарны үтәргә, Ул тыйган нәрсәләрдән тыелырга кирәк, — диде Нурулла хәзрәт. — Әйтик, намаз укымасаң, хәрам ризык ашасаң, дога кылып Аллаһы Тәгаләдән нәрсәдер сорау бик читен бит ул, сеңлем.

— И хәзрәт, инде биш елдан артык намазда, Аллага шөкер... Чиста күңел белән, хәрамләшмичә яшәргә тырышам, әлхәмдү лилләһ!

Мондый җавапны ишеткәч, имам болай диде:

— Рәхмәт, сеңлем, бик рәхмәт, ихлас кылган гамәл-гыйбадәтләрегез кабул булсын! Ә дога-теләкләрнең кабул ителмәве хәерлегә дә булырга мөмкин.

Киңәш сорарга дип килгән хатын: "Ничек инде шулай?" — дип гаҗәпләнүен белдергәч, Нурулла хәзрәт үзенең имамлык чорында булган гыйбрәтле дә, хикмәтле дә хәлне исенә төшереп, сөйләргә булды.

— Берничә ел элек мәчеткә сезнең яшьләрдәге бер ханым килеп керде. Елый-елый сәдакасын сузып, дога кылуымны үтенде ул. Тормыш иптәше вафатына инде бер ел булган, ә ул аны һаман оныта алмый һәм... һаман үкенә икән... Нәрсә булганын сөйләвен үтенгәч, ул күңелен ачып, күз яшьләре белән сугарылган тормыш вакыйгасын бәян итте.

"Ирем бик әйбәт кеше иде, әмма эше буенча командировкаларга еш йөрде. Кайчакта берничә көнгә чыгып китә, кайвакытта ике-өч атнага, бер айдан артык эш сәфәрендә йөреп кайткан чаклары да күп булды. Бу миңа һич тә ошамый иде. Иремнең өйдән чыгып китеп, атналар, айлар буе читтә йөрүеннән тәмам туйгач, дога кылып: "Йә Раббым, ирем гел янымда гына булсын, беркая да китмәсен иде!" — дип Аллаһы Тәгаләдән ялварып сорый башладым. Ике ел дәвамында берниндә дә үзгәреш булмады, әмма мин өметемне өзмичә дога кылуымны дәвам иттем һәм көннәрдән бер көнне... иптәшемнең эшеннән шалтыратып, шомлы хәбәр җиткерделәр: "Ирегезне авыр хәлдә хастаханәгә алып киттеләр, шунда барсагыз иде...".

Хастаханәдә озак кына яткырганнан соң, иремне өйгә озаттылар: носилка белән "Ашыгыч ярдәм" машинасына күчереп, без яши торган йортка күтәреп кертеп куйдылар. Ни булганын аңлап та бетерә алмадым: паралич сугып, ул бөтенләй хәрәкәтсез калган иде. Шуннан ел ярым өйдә урын өстендә ятканнан соң, ирем күзләрен мәңгелеккә йомып, бакыйлыкка күчте. Кадерлем гел янымда торып, бәхетле булырмын дип хыялланган идем югыйсә, әмма догада дөрес сорый белмәгәнмен шул...".

— Менә шундый гыйбрәтле сабак, сеңлем, — дип тәмамлап куйды хикәятен имам.

— Кайчакта без бик тә теләгән нәрсәнең тормышка ашмавы хәерлегә дә булырга мөмкин.

Хәзрәт бүлмәсенә кергән хатын беравык сүзсез утырды. Бераздан исә, аңына килгәндәй, башын күтәрде дә, әкрен генә әйтеп куйды:

— Алай икә-ән... Сорый белсәң — теләк, сорый белмәсәң...

Шуннан соң йөрәге "дөп-дөп" килгәнен тойгангадыр, ханым кинәт кенә торды да, бүлмәнең ишегенә таба кызу-кызу атлады. Нурулла хәзрәт исә, ихлас кызыксынуын белдереп, сорап куйды:

— Ашыкма әле, сеңлем, хыялың турында берни әйтмәдең ич, синең тормыш иптәшең кайда эшли?

Бермәлгә ишек төбендә туктап, ханым башын хәзрәт ягына борды да, кысылган ирennәрe аша берничә генә сүз кысып чыгарды:

— Кайда эшләсен? Шунда инде, шунда...

Шуннан соң бүлмәдән чыгып ишекне япты да, күңеле тулып елап җибәрде. Бу мизгелдә ул бик мөһим бер нәрсәне аңлап, Раббысына шөкер хисләрен җиткерде һәм фикере белән элек кылган догаларын төзәтә-төзәтә, үзенә бик тә кадерле булган кешесен күрергә дип өенә ашыкты.

**Ришат Курамшин,**
**Кукмара мәдрәсәсе директоры.**

# Мөселман активы өчен шәһәр күләмендә ифтар



13 июньдә Чаллының “Аш-Су” ресторанында шәһәр мөселман активы өчен традицион ифтар мәҗлесе үтте. Анда 200 кеше катнашты. Мәҗлескә кадәр шәһәр имамнары җыелышы булды. Ул үз мәхәлләләрендә имам итеп сайланучыларга шаһәдәтнамә тапшырудан башланды. Бу күңелле эшне мөфтинең мөхтәсибәтләр белән эшләү буенча яңа урынбасары Мансур хәзрәт Җәләлетдинов башкарды. Җәмгысе 15 имам-хатыйб аның кулыннан яңа срокка шаһәдәтнамәләр кабул итеп алдылар. Шуны да әйтик, быелы сайлауларда шәһәрнең имамнар составы үзгәрмәде. Алар бу савапны эшне алдагы елда да дәвам итәчәк. Җыелышта катнашкан нәзарәт юристы Айрат хәзрәт Билалов әйтүенчә, шаһәдәтнамәләр бер, ике елга бирелә. Аннары имамнарга аттестация үткәрү юлы белән аларның срогы озынайтылачак.



Яңа срокка вәкаләт алган имамнар үз чиратында шәһәр имам-мөхтәсибен сайладылар. Җыелышка бу уңайдан мөфти хәзрәт тәкъдимен Мансур хәзрәт җиткерде. Бу вазыйфага кабаттан Әлфәс хәзрәт Гайфуллин тәкъдим ителде. Имамнар бертавыштан аның кандидатурасын хуплады һәм аны яклап бердәм тавыш бирде. Аннары җыелыш биш кешедән мөхтәсибәт Шурасы һәм өч кешедән ревизия комиссиясе составларын сайлады. Шуның белән ул үзенең эшен тәмамлады.





Имамнар җыелышы барган арада ифтарга җыелган халыкка “Ак мәчет” мәдрәсәсе мөгаллиме Азат хәзрәт Шәрипов эчтәлекле вәгазь сөйләде. Мәҗлескә килүчеләрне мөфти урынбасары Мансур хәзрәт Җәләлетдинов, шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Рамил Хәлимов сәламләделәр, Аллаһы ризалыгы өчен булган ошбу гыйбадәтне үтәүдә шәһәрдәшләребезгә җиңеллекләр теләделәр. Алар шулай ук Әлфәс хәзрәтне имам-мөхтәсиб итеп сайлану, ә имамнарны шаһәдәтнамә алу белән котладылар.



Ахшам намазыннан соң авыз ачу мәҗлесе булды.

**Рәсемнәрдә:** Мансур хәзрәт иң яшь имамнарның берсе “Рамазан” мәчете имам-хатыйбы Фәрхәд хәзрәт Гайфулинга шаһәдәтнамә тапшыра; җыелыш бара; мәҗлестән күренешләр; Әлфәс хәзрәт чыгыш ясый.

# Рамазан бизәкләре



**Чаллының “Сөембикә” мәчетендә тәрәвих намазы. Бирдә Коръән-хафиз Акбарша хәзрәт имамлыгында тәрәвих намазларында Коръән хәтем кылынды;**



**Пермь крае Барда районы Аклыш авылы мәчете имам-хатыйбы Фидәил хәзрәт Илкәев тәрәвих намазына килүче яшьләр белән;**



**Чаллының “Кәүсәр” мәчетендә имам-хатыйб Фәрит хәзрәт Фатыйхның мәчет картлары һәм шәһәр имамнары өчен уздырган авыз ачу мәҗлесеннән күренеш;**



**Чаллының “Әбүзәр” мәчетендә ифтар.**

**Нәшире**
**Иршат Гыйльметдин улы ШӘЙХАТТАР**

**Баш мөхәррире**
**Хәлил ШӘРИФ**

**Тел.:** (8552) 70-51-09
**Факс:** (8552) 70-51-45

* * *

**Оештыручылары:**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, “Ислам нуры” дини эшмәкәрлек Үзәге

Газетабыз мәкаләләрен күчереп басканда аларның “Ислам нуры”ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән язмалар игътибар белән өйрәнелә, рецензияләнә. Хатлар газетага әзерләнгәндә авторларның стиле саклана.

**Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.**

**Электрон хатлар өчен:**
**e-mail: islamnury@mail.ru**

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучылар сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җаваплар бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

“Роспечать” агентлыгы каталогына кертелгән, язылу ел әйләнәсендә Россия Федерациясе буенча алып барыла.

Айга ике мәртәбә чыга.

**Тиражы 1100.**

**Индексы 54149**

* * *

Хөрмәтле укучыбыз!

Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга, алай дабулмаса башка мөселманнарга тапшырсагыз иде. “Ислам нуры”ның һәр саны кулдан-кулга күчеп динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетабызны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан сакланырлар дип ышанабыз.

* * *

Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән “Ислам нуры” басмаханәсендә басылды.

Нәшир һәм редакция адресы:
**423802, Яр Чаллы, Үзәк урамы, 72**

**Басарга кул куелды:**
**график буенча**
**20 июнь 16 сәг.**
**фактта 20 июнь 16 сәг.**

**Бәясе ирекле**